**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.05.2020 № 569

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 апрелендәге 434 номерлы «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карары белән расланган Суд тәртибендә эшкә сәләтсез яки эшкә сәләтсез дип танылган балигъ булмаган затны опекун яки попечитель билгеләү буенча муниципаль берәмлекләр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 16 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 2009 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 апрелендәге 434 номерлы «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карары белән расланган Суд тәртибендә эшкә сәләтсез яки эшкә сәләтсез дип танылган балигъ булмаган затны опекун яки попечитель билгеләү буенча муниципаль берәмлекләр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктының 6 пунктчасын төшереп калдырырга;

2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«- «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында булган инвалидлык турында белешмәләр.».

2. Әлеге карар 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин